Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Шекше торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

08.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 22 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең Шекше торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Шекше авыл җирлеге Шекше торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Шекше авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;

-Күмү урыннарын карап тоту: Шекше авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/ shikshi бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шекше авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәйртдинов